

Рузаевка районындагы Татар Пеш-ләсе авылы елдан-ел тозекләнә бара. Кvптән тvгел биредә яна спорт мәйданы тозелде. Ә Овражная урамындагы  автомобиль юлын ремонтлыйлар.
Рузаевка районы житәкчесе Александр Борисович Юткин болай ди: «Татар Пешләсе авылы депутатлары белән халык кvптән инде Овражная урамы автомобиль юлын ремонтлау теләген белдереп морәжәгать итеп килделәр.      Бvген, «Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары» милли программа нигезендә, бу урам буенча vткән бормалы 2 километр юлны ремотлауга 12 миллион акча бvлеп бирелде. Эшчеләр юлны тырышып ремонтлыйлар; авыл администрациясе житәкчесе бу объектта еш була».
Ә «Авыл территорияләрен комплекс-лы vстерv» программасы кысаларында Татар Пешләсе авылы уртасында урам тренажорлы спорт мәйданы булдырганнар. Аны тозv очен 1700 мен сум акча бvлеп бирелгән. Шулай ук, авыл администрациясе житәкчесе Ринат Дявлюк улы Шабаев әйткәнчә: «... янәшәдә генә минифутбол белән волейбол мәйданнары да булдырырбыз».
Авыл халкы да бу эштән читтә тормый: яшәгән жирләрен һаман ямьләндереп торалар. Һәрбер эштә ярдәмчеләр табылып тора. Мәсәлән, яз башлану белән Шәриф Камал ташы тирә-ягын жыештырып алганнар, чә-чәкләр утырткannар, утап-коеп торалар. Биредә кvбрәк мәгариф-мәдәният олкәсе алдынгылар: укучылар, укытучылары белән бергә... Волейбол-футбол мәйданынын каты катламын жәяргә, аннары матурларга булышучылар санын санап китеп булмый – алар кvп.
«Чиста авыл» дигән традицион акция кысаларында Татар Пешлә авылы волонтерлары яна спорт мәйданы яны территориясен матурлап та куйганнар. Ә бит дорестән дә: һәр кеше vз әйләнә-тирәсен матуррак, яхшырак, яшәv очен унайлырак итәргә тырышырга тиеш. Бу без яши торган урынга да кагыла.

**Наилә НАСЫРОВА**